# *Гимназияне төрле елларда белем алган көрәшчеләр белән очрашу*

## *23 апрель, 2016 ел*

***"Егетләрнең асыллары көрәшеп бил ныгыта!"***
***Яшь батырлар үзебездә***
***Эзләмәгез әллә кайдан,***
***Тик кирәкми аларга дан-***
***Кирәк мәйдан, киңрәк мәйдан!***

***10.45 сәгать. Ишек каршында курайчылар ансамбле халык көйләрен уйный. Кунакларны яшь көрәшчеләр һәм 4 укучы каршы ала.***

**1аб**. *Гимназияне белем алган һәм төрле дәрәҗәдәге көрәш бәйгеләрендә мәктәп данын яклаган укучыларыбыз белән очрашу - безнең өчен зур мәртәбә.*

**2аб.***Татар халкының кунакчыллык бәйгесе булган чәкчәк – безнең сезгә хөрмәтебез билгесе. Чәкчәктән авыз итегез!*

***3аб.*** *Көрәшеп, гимназиягә күп мәртәбәләрҗиңү алып кайткан хөрмәтле укучыларыбызга Гатина Л.В. җитәкчелегендәге Экспрессия" ансамбле бию бүләк итә. (Татар халык биюе башкарыла, биючеләр коридор ясап басалар).*

***4аб.*** *Йолдызлы юлдан Актлар залына рәхим итегез, хөрмәтле көрәшчеләребез!*

*"Футболчылар гимны" астында көрәшчеләр футболкалары кигән 2а классы яшь көрәшчеләе кунакларны Актлар залына җитәкләп алып керәләр, алгы рәткә утырталар, үзләре арткы рәткә утыралар.* Залда көрәшчеләрне " Бәхетле балачак" вокаль ансамбле каршы ала, " Туган ил" җыры башкарыла. Җитәкчесе Зәйнуллина Ә.Т.




**Алып баручылар чыга.**

**<u>1 аб- Энҗе Әзгамовна</u>:** Хәерле көн бар дөньяга!
Хәерле көн, Туган илем!
Илем-көнем, динем, телем,
Сөекле халкым минем!

**<u>2 аб</u>:** Хәерле көн барчагызга:
Олыгызга, кечегезгә,
Газиз мөгалләмнәр - сезгә,
Көрәшчеләр,
Сабакташлар, һәммәгезгә,
Сөекле җиребезгә!

**1аб.** Гимназиядә бүген гадәти булмаган тантана! Уку йорты бүген үзенең лачыннарын - көрәш батырларын - ниһаять, бергә җыйды!



1989-2016 нчы елларда гимназиядә Татарстанның иң яхшы тренерларының берсе **Шәмсевәлиев Илгиз Вагыйзь улы** җитәкчелегендә татар көрәшчеләренең берничә буыны үсеп чыкты. Бүген залда үзләренең көч – куәтләре, ихтыяр көчләре, көрәш осталыклары белән күп мәртәбәләр гимназиягә җиңү китергән хөрмәтле укучыларыбыз - көрәшчеләре утыра! Алар бүген, вакыт табып, укытучылары, тренерлары, иптәшләре белән күрешү өчен, газиз мәктәпләренә кунакка килде. Бу истәлекле очрашу мәктәпнең 110 еллык юбилеена әзерлек көннәрендә үткәрелү – үзе бер мәртәбә! Хәзер укучыларның алкышлары астында кунакларыбызны сәхнәбез түренә чакырабыз:

Менә алар( чиратлап атыйлар):

- Хәйруллин Салават Рашат улы1978) ;
- Бертуган Рузил (1978) һәм Рәмзил (1981) Шәйхразиевлар ;
- Мингалиев Ринат Дилшат улы (1994);
- Гыйләҗетдинов Ранис (1995);
- Камалов Рафаэль(1996);
- Халиуллин Алмаз - 9а классы;
- - Камалов Дамир- 7 г классы.

*Алар республикада гына түгел, Рәсәй күләмендә күп мәртәбәләр җиңүләр яуладылар, сабантуй мәйданнарын тоттылар. Дуслар, өйдәгез, аягүрә басып, үзебезнең көрәш батырларын хөрмәтлик әле!*

**( Алкышлар. Кунаклар һәм укучылар утыралар).**



**Чараны укытучы Нурисламова Э.Ә. һәм 6б класс укучысы Данияр алып барды**



**Хәлимов Ф.Г. җитәкчелегендәге курайчылар ансамбле көрәшчеләрне сәламли**

**2аб.** Татар көрәшенең мең еллык тарихы бар. Борынгы кабиләләр, үз сугышчыларын көчле, җитез итеп тәрбияләү өчен, бер - берсе белән көрәштергәннәр, аларны лаеклы ир-егет итеп үстерергә омтылганнар. Татар егете аягына басу белән көрәшә башлый, көчле булганлыгын расларга тырыша. Узган гасыр урталарында көрәш милли спорт төре буларак формалаша. Татар көрәше милләтне бергә туплау, үстерүгә дә ярдәм итә.




**1аб.** Яшь батырлар үзебездә
Эзләмәгез әллә кайдан,
Тик кирәкми аларга дан -
Кирәк мәйдан, киңрәк мәйдан!

**2аб.** Хөрмәтле кунаклар, хәтерлисездер, без бик күп көрәш бәйгеләрен шушы шигырь юллары белән башлап җибәрә идек. Бәйгеләрне оештыручы, көрәшкә әзерләүче, шәкертләре белән бергә җиңү шатлыкларын уртаклашучы һәм җиңелү ачысын да бергә кичерүче *Шәмсевалиев Илгиз Вәгыйзь улы* булды. Аның 2 гимназиядә эшли башлавына бу уку елында 23 ел тулды. Илгиз Вәгыйзович өч тапкыр "Татарстанның иң яхшы тренеры" исеменә лаек булды (2007, 2009, 2011). Ул 2012 елдан "ТР ның физик спорт отличнигы" дигән мактаулы исем йөртә. Гимназия көрәшчеләре шундый зур уңышларга ирешкән һәм уку йортының республикада татар милли көрәше буенча абруйлы үз урыны барлыкка килгән икән, бу, әлбәттә - остазлары Илгиз Вәгыйзовичның да хезмәте.



*-Илгиз Вәгыйзович, Сез үзегез милли көрәшкә ничек килдегез? Гимназиядә хезмәт юлыгызны ничек башладыгыз? Кайсы ярышлар бигрәк тә хәтерегездә саклана*?

**Илгиз Вагизович:** Авыл хуҗалыгы институтында 3 ел көрәш белән шөгыльләндем. 1993 елның октябрь аенда, 2-3 тапкыр чакыргач, риза булып гимназиядә эшли башладым. Минем тренер тәҗрибәм юк иде. Шуңа карамастан, 2-3 ел эчендә яхшы команда туплый алдык. Алабугада уңышлы чыгыш ясадык, 2 гимназиядә оештырылган ярышта республика буенча 2 нче урын алдык.



**1996 елда 25 команданы җиңеп, 2 гимназия командасы җиңүче булды**

Соңгы елларда балалар көрәше алга китте. Команданың 80-90 % ы 2 гимн-зия укучылары. Соңгы биш елда елга 2 тапкыр гимназиянең үзендә шәһәр көрәш бәйгеләре үткәрү традициягә керде.



**Елның иң яхшы өч тренеры.**








***2аб.:*** *3 в класс укучысы Ишалина Айсылу башкарачак “Сайра, сандугач”җыры тренер Шәмсевалиев Илгиз Вәгыйзович һәм 2 гимназиядә эшләгән тренерлар хөрмәтенә башкарыла .*




**1аб.** Сезне бүгенге очрашуга кайта алмаган танылган көрәшчеләребезнең берсе, бүгенге көндә ТР Президентның дин эшләре буенча Киңәшчесе Илдар Сәлаховның котлау телеграммасы белән таныштырырга рөхсәт итегез!

**Телеграмма:**



***Хөрмәтле укытучыларым, кадерле дусларым! Сезне барыгызны да чын күңелдән кайнар сәламлим! Шундый күркәм мәҗлескә чакырганыгыз өчен зур рәхмәт! Барыгызга да алдагы тормышта тагын да биек үрләр яулауны телим. Без мәктәбебез белән горурланган кебек, мәктәбебез дә безнең белән горурланырлык булсын! Ихтирам белән Илдар Салахов.***

**2аб.** Мәктәп елларында Хәйруллин Салаватны укытучылары яратып “Салават-Батыр” дип йөрткәннәр, чөнки ул гимназиядә укыганда ук, көндәшләрен чистага салып, күп төрле ярышларда җиңеп, гимназия данын еракларга тараткан.





- Салават Рашатович, безне үзегез белән якыннанрак таныштырыгыз әле. Спорт сезгә киләчәк һөнәрегезне сайлаганда ничек ярдәм итте?

**Хәйруллин Салават Рашатович сөйли:**

Мин, 4-5 классларда укыганда, “Витязь”да грек - рим көрәше белән шөгыльләндем. Туксанынчы елларда гимназиягә Илгиз абый эшкә килгәч, милли көрәш белән шөгыльләнә башладым. Казанда, Мамадышта оештырылган бәйгеләрдә җиңүләргә ирештем. КФУ ны, аспирантураны уңышлы тәмамладым. Диссертация яклап, “Техник фәннәр кандидаты” дигән исем алдым. Бүгенге көндә ГИБДД Дәүләт инспекциясендә эшлим. Гаиләм бар. Улым да спорт белән шөгыльләнә.




**1аб.** Сәхнәгә, яшь булуына карамастан, көрәштә зур уңышларга ирешкән спортчыларыбызның берсен - 40медаль иясен - биюче,” Татар малае-2016” бәйгесендә финалга чыккан Дамир Камаловны чакырабыз.

**Дамир Камалов чыгышы**








**2аб.** Бертуган Рузил һәм Рәмзил Шәйхразиевларның берсе - бүген Казан каласында һәм икенчесе Актаныштa яшиләр. Кызганычка каршы, алар очрашуга кайта алмадылар.




Сул яктан Радик, Салахов Илдар, тренер Илгиз Шәмсевәлиев,
Хәйруллин Салават,  Шәйхразиев Рузил













**Шәйхразиев Рузил Камил улы – Муса Җәлил призы -1994 ел – 1 урын, Актаныш сабантуе батыры- 1994, 1995, 1996 еллар.**




**1аб.** Бертуган Хамадиевалар көрәшчеләргә һинд биюен бүләк итә.

**Бертуган Хамадиевалар чыгышы.**

**1аб.** Хәлимов Ф.Г. җитәкчелегендә курайчылар ансамбле гимназиядә үткәрелгән күп бәйгеләрдә чыгышлары белән көрәшчеләребезне җиңүгә рухландырдылар. Бүгенге очрашуга да алар музыкаль күчтәнәч белән килделәр.




**Курайчылар  ансамбле чыгышы.**

**2аб.** Көрәш - ул татарның кодрәтен күрсәтә торган спорт төре. Безнең халыкта көрәш рухы бервакытта да югалмаган.Төрле бәйрәмнәрдә, сабан-туйларда бил алышу, буыннан буынга күчеп, камилләшеп, бүгенге көнгә килеп җиткән. Татарлар яши торган төбәкләрендә татарча көрәш торган саен популярлаша бара.

Хәзер мин сезне мәктәптә укыган елларда ук Сабантуйлар токан тагы берничә көрәшче егет белән таныштырам. Алар бер чорда, күрше классларда укыган егетләр - **Мингалиев Ринат (1994), Гыйләҗетдинов Ранис (1995).**



- Егетләр, нинди Сабантуйларда оттыгыз һәм оттырдыгыз? Җиңгән һәм җиңелгән чакта нинди хисләр кичерәсез? Әти-әниләрегезнең мөнәсәбәте ничек?

**Мингалиев Ринат :** 15-16 яшьтә беренче тәкә алдым . Көрәшеп алынган тәкәләр 15-20 ләп булыр инде. Әти-әниләр дә, үзем дә горурланабыз.

- Соңгы елларда көрәшчеләргә билгеле бер вакыт биреп, көндәшен баш аркылы оста алым белән чөеп җибәрергә яки аркасы белән төшерергә дә кайвакыт мөмкинлек бирмиләр. Кайвакыт, җиңү сезнең якта булса да , казыйларның көрәш кагыйдәләрен бозу очраклары бар. Болар сезнең күңелегезне төшермиме?

**Гыйләҗетдинов Ранис :** Мин үземнең беренче укытучым Закирова С.М. га рәхмәтлемен. Ул мине көрәш юлына кертеп җибәрде.



**Илгиз Вагизович:** Мингалиев Ринат билбау көрәше буенча спорт мастеры исеменә лаек булды. Ул мин әзерләгән биш спорт мастерының берсе!

**1аб.** Көрәш буенча гимназиядә иң күп җиңүләргә ирешкән спортларның берсе һәм, ялгышмасам, 60-70 медаль иясе Камалов Рафаэльгә көрәш ярышлары күп тапкырлар ярыш флагын күтәрү ышанып тапшырыла. Республика көрәш турнирларында күп тапкырлар җиңүче, Сабантуйларның абсолют батыры һәм милли көрәш буенча ТР сы чемпионы Камалов Рафаэль турында газеталардә мәкаләләр басылып чыга. Мөслим төбәге хөрмәтле врачларының берсе Фатих Камаловның оныгы Рафаэль Камалов мәктәпне тәмамлагач, тагы нинди уңышларга ирешкән? Киләчәккә нинди планнары бар?




**Камалов Рафаэль :** КФУ да укыйм. Имтиханнар бара. Армиягә барачакмын. Алга таба балалар белән шөгыльләнергә уйлыйм.



**2аб**. Гимназия көрәшчеләре бүгенге көндә дә сезнең традицияләрне уңышлы дәвам итәләр**.** Яңа буын көрәшчеләр җиңү артыннан җиңү яулыйлар. Шундый көрәшчеләребезнең берсе 9а классы укучысы Халиуллин Алмаз һәм Камалов Дамир бу уку елында милли көрәш буенча Россия бәйгеләрендә призлы урын алды.исемнәренә лаек булды.

**Халиуллин Алмаз һәм Камалов Дамир белән таныштыру**.



**1аб.** Сәхнәгә көрәш бәйгеләрен оештыруда башлап йөргән, һәр  көрәшчене үз улы кебек якын итеп, аларның  һәр уңышын күңелендә     саклаучы, чирек гасыр гимназиядә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләүче Татарстанның атказанган  укытучысы Харисова Э.М. ны сәхнәгә чакырабыз.

**Харисова Э.М. чыгышы:**

***Сәхнәбез түрендә утырган  көрәшчеләребез үзләре дә кайчан гына әле укучылар иде.  Мәктәп елларында аларга уку белән спортны бергә алып бару,  югары дәрәҗәләргә ирешү, көрәшче исемен тиешле югарылыкта саклап йөртү   бер дә җиңел булмагандыр.  Хөрмәтле  көрәшчеләребез - мәктәп елларында  үзегезнең җиңүләрегез  белән мәктәпне  данга күмгән кадерле  укучыларыбыз!   Сезнең  гимназиябез  тарихында  абруйлы  үз урыныгыз бар! Тормыш дәвам итә. Бүген әнә  тормышта үз урыннарын тапкан, җиргә  ышанычлы, кыю адымнар белән   атлап баручы ир - егетләр булгансыз, күпләрегезнең  гаиләре бар, балалар   үстерәсез.  Мин икеләнмичә әйтә алам: көрәштә генә түгел,  эш урыннарында, гаиләдә  дә таяныч  булырлык ир-егетләр, гаилә топкалары сез!***

***Мәктәптә укыган  вакытта, бәлкем, без  Сезгә тиешле рәхмәтебезне дә җиткерә алмаганбыздыр. Ләкин без  сезне  бик ярата идек,  батыр егетләребезнең һәр уңышына сөенә идек.***

***Салган сукмакларыгыз, мәктәптә калдырган эшләрегез горурланырлык.  Көрәш мәйданнарында гына түгел, тормыш мәйданнарында да  КӨРӘШЧЕ  дигән исемне югары йөртегез!***

***Шушындый   батыр көрәшчеләр   тәрбияләүдә зур хезмәт куйган Шәмсевәлиев И.В. ка  рәхмәтемне җиткерәм!***

***Без сезнең һәрберегезне гимназиянең 110 еллык юбилеенда көтеп калабыз! Нинди генә тормыш мәшәкатьләре булса да кайтмый***

***калмагыз! Сез килмәсәгез, безнең бәйрәмебез түгәрәк булмас! Бүгенге бәйрәмгә килүегез өчен Рәхмәт!***

**2аб.** Хөрмәтле кунаклар! Очрашуыбыз ахырына якынлашты. Кичәбез ахырында бергәләп фоторәсемгә төшү - бүгенге очрашуның бер матур истәлеге булсын.

*(Фоторәсемгә төшү)*

Мөхтәрәм көрәшчеләрне спортзалга чакырабыз! 13.00 сәгатьтә анда гимназиянең 110 еллыгына багышланган Көрәш бәйгече башланачак!

Сценарий авторы - Харисова Э.М. Чараны Нурисламова Э.Ә .алып барды.

Очрашуны 6 класс җитәкчеләре Каюмов Р.Г., Ризванова Г.Ф., Мухаметшина З.К.әзерләде һәм Гатина Л.В., Халимов Ф.Г., Зәйнуллина Ә.Т.җитәкчелегендәге ансамбльләр катнашты.

## ***Гимназиянең 110 еллык юбилеена багышланган***

## ***көрәш бәйгесе-2016***

***Марш уйнала.***

(Бәйгедә катнашучылар **марш** астында чыгып төзелә.)

Тренер: Парад, стой!
Парад! Равняйсь!Смирно!
Равнение на середину!

**1 аб:** Хәерле көн, кадерле дуслар! Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, спорт ветераннары, тренерлар һәм көрәшчеләр!

**2 аб:** Бүген Мулланур Вахитов исемендәге 2нче гимназиядә 2003-2008 нче елгы ир балалар арасында г***имназиянең 110 еллык юбилеена багышланган*** көрәш бәйгесе оештырыла. Тантанада түбәндәге мактаулы кунаклар катнаша:

**1аб.** “Витязь” спорт мәктәбе директоры, Яр Чаллы шәһәре милли татар-башкорт көрәше Федерациясе директоры **Гыйрьфанов Рәшит Дим улы;**
**2аб**. РФ һәм ТР ның атказанган тренеры, милли көрәш буенча спорт мастеры, профессор **Фәйзуллин Рәкыйп Нәҗип улы.**

***1аб. Бәйге шуның белән үзенчәлекле: бүген төрле елларда гимназиядә укыган һәм төрле дәрәҗәдәге ярышларда гимназия данын яклаган данлыклы көрәшчеләр катнаша:***

- **Хәйруллин Салават Рашат улы;**
- **Мингалиев Ринат Дилшат улы ;**
- **Гыйләҗетдинов Ранис ;**
- **Камалов Рафаэль һ.б.;**

**2аб.** Ярышны ачу өчен сүз гимназия директоры **Аюпова Фирдүсә Фәнәвис кызына** бирелә. (**Директор чыгышы**).

**1аб:** Республика көрәш турнирларында күп тапкырлар җиңүче, Сабантуйларның абсолют батыры һәм милли көрәш буенча РФ се чемпионнары Халиуллин Алмаз һәм Камалов Дамир, флагны күтәрү өчен, мәйдан уртасына чакырыла.
**(Гимн** башкарыла.**)**

**1 аб:** Көрәш бәйгесендә Яр Чаллы шәһәренең 2 нче гимназиясеннән, 29 нчы гимназиядән, 52 , 75 нче мәктәптән, “Витязь” спорт мәктәпләреннән һәм Алабуга шәһәре 1 нче гимназиясеннән яшь көрәшчеләр катнаша. Әйдәгез, кул чабып, командаларны сәламлик!

**1 аб:** Ярышның казыйлары (судьялары) белән таныштырабыз:

- Бәйгенең баш казые - республика категорияле судья **Шәмсевалиев Илгиз Вәгыйзович**
- Баш сәркатип – 1нче категорияле судья **Хәйбуллин Илнур Нурисламович.**

*1 аб.:* Сүз баш судья **Илгиз Вәгыйзовичка** бирелә.

**2 аб:** Көрәш бәйгесен оештыру һәм үткәрү өчен зур булышлык күрсәткән спонсорларга рәхмәтебезне җиткерәбез. Көчле алкышлар аларга!

**1аб.: Көрәшчеләр төркеме сезнең игътибарга күрсәтмә чыгыш тәкъдим итә. Җитәкчесе –Шәмсевәлиев Илгиз Вәгыйзович.**

**2 аб.:** Кадерле дуслар! Көрәшчеләребезгә - уңышлы чыгышлар, казыйларга гаделлек телибез. Чараның тантаналы өлеше тәмам. Шуның белән парадны ябык дип игълан итәм. (**Марш уйнала**. Спортсменнар марш астында чыгалар). Тагын бер тапкыр уңышлар сезгә!

Сценарий авторы Харисова Э.М.

***Бәйгедә 2 гимназия командасы 1 нче урын алды.***